БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №9 (7026) | 23 январь, 1990 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

## СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

## СССР Верховный Советын чакыру турында

СССР Верховный Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советының өченче сессиясен 1990 елның 14 февралендә Мәскәү шәһәрендә чакырырга.

**СССР Верховный Советы Председателе М. ГОРБАЧЕВ.**

Мәскәү, Кремль, 1990 ел, 16 январь.

## Район сайлаулар алдыннан

### Социалистик ярышта алдынгылар

Мичурин исемендәге колхозның Урта Камышлы авылы терлекчеләре үзган ел хуҗалыкларга һәркайсы 440 килограммлы 1085 баш башмак тана тапшырдылар. Аларның яртысы элита һәм икенче яртысы элита-рекорд класслы.

Фермада хезмәт юлын кечкенәдән шунда башлаган, тәҗрибәле, оста терлекчеләр эшли. Аларның берсе Алексей Федорович Кульметьевның рәсеме район Почет тактасында, ә В. С. Кульметьев рәсеме колхоз Почет тактасында тора. Алар В. И. Леонтьев белән бер группада эшләп, планны 142 процентка үтәделәр.

В. Захаров бөтен гомерен шул фермада эшләп үткәргән кеше, беренче класслы терлекче. Ул планны 128 процентка җиткереп үтәде. А. Щербаков яшь булса да, оста терлекчеләрдән күпкә калышмый.

**А. САВГАЧЕВ,**
зоотехник.

**«Таң» колхозында Госман Галиевич Сәйфуллинны унган терлекче буларак һәркем ихтирам итә. Ул терлекчелек тармагында ике дистә ел эшли инде. Шул чорда бу хезмәтнең ачысын да, төчесен дә татыды. Кышын мөгезле эре терлекләргә азык кайтара, җәй айларында ул малларны көтә. Иртә таңнан кичке караңгыга кадәр фермадан кайтып керми ул. Шуңа да хезмәттәшләре арасында абруе зур аның.**

**Бүгенге көндә Госман Галиевич Хәмидә Галимова һәм Минзадә Гәрәева карый торган терлекләргә азык ташый. Сыер савучыларга башка эшләрне башкаруда да ярдәм итә. Терлекчеләр дус-тату эшләп, маллардан көн саен уртача 10 килограмм сөт савып алалар.**



## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

### Икеләтә арзан

**Архангельскида ачылган яңа ателье ветераннар бюджетына исәп тотып салынды. Аның исеме дә «Ветеран». Ул пенсионерларга гына хезмәт күрсәтә. Олы яшьтәгеләр өчен өс киеме һәм күлмәк тегү гадәти ательелардагыдан икеләтә арзангарак төшә.**

* * *

### Уңыш мул булды

**Карелия урманнарына керсәң, чыгасың да килмәс. Һәркайда аклык, пакълек. Чыршылар алтынсыман күркәләр белән бизәлгән. Күп еллар инде күркә уңышының былелгыдай мул булганын хәтерләмиләр монда. Урманчылар «урак өсте»нең беренче атналарында гына төньяк тайгасы «королевасы»ннан 1700 тонна уңыш җыеп алдылар. Кыш азагына кадәр тагын шулкадәр күркә җыелачак.**

* * *

### Колхозда—АТС

**«Мәскәү» колхозында (Ленинабад өлкәсе) 250 номерлы тагын бер АТС төзелү белән крестьян гаиләләренең гозерләре канәгатьләнделәр. Торак кварталлардан тыш, яңа иҗтимагый үзәккә, мәктәпкәчә балалар учреждениеләренә, поликлиникага да элемтә линияләре суздылар. Яңа АТСны колхоз үз акчасына төзетте.**

* * *

### Эштән соң төзеп

**Молдавия ССРның Бельцы төзелеш трестыннан Н. Омельян җитәкчелегендәге комплекслы бригада члennары эштән буш вакытларында 50 квартиралы йорт салдылар. Аңа Яңа елның беренче көннәрендә төзүчеләр үзләре урнаштылар.**

## РӘСМИ ХРОНИКА

### Секретарь сайланды

18 январьда «40 лет Победы» колхозы башлангыч партоешмасында партия җыелышы булып үтте. Анда Әнвәр Мингәрәевич Шәяхмәтов партоешма секретаре итеп сайланды.

Җыелышта КПСС райкомы бюросы члены, райкомның партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге мөдире Ф. Ш. Галимов катнашты һәм чыгыш ясады.

### Ә. М. ШӘЯХМӘТОВ

Әнвәр Мингәрәевич Шәяхмәтов Татарстан АССРның Октябрь районы Чулпан авылында 1963 елда туган. 1987 елдан КПСС члены.

Ә. М. Шәяхмәтов үзенең хезмәт юлын 1980 елда «Путь к коммунизму» колхозында комбайнчы ярдәмчесе булып башлый. 1981—1983 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Хезмәт срогын тутырып кайткач шул ук хуҗалыкта шофер булып эшли. 1984 елдан 1988 елга кадәр М. Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтында укый. 1989 елның декабренә кадәр шул ук институтның комсомол комитеты секретаре вазифаларын башкара.

## Оборона-масса эше айлыгы башланды

19 январьда район культура йортында Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты төзелүнең 72 еллыгы уңаеннан оборона-масса эше айлыгы ачылуга багышланган тантаналы җыелыш булып үтте.

Җыелышта кереш сүз белән КПСС райкомының идеология бүлеге мөдире Р. Ф. Җамалиев чыкты. Ул катнашучы сугыш һәм хезмәт ветераннарын, сугышчы-интернационалистларны, район промышленность предприятиеләре һәм колхоз-совхозларның башлангыч партия һәм комсомол оешмалары секретарьларын һәм шәһәр мәктәпләре укучыларын айлык башлану уңаеннан кайнар тәбрикләде.

Аннары Октябрь районы хәрби комиссары И. М. Бовин чыгыш ясады. Җыелыштагыларны СССР Кораллы Көчләренең данлыклы юлы белән һәм районда комсомол-яшьләр арасында үткәреләчәк чаралар белән таныштырды.

Сугыш һәм хезмәт ветераннары А. Д. Дмитриев, Н. И. Маслаков, И. Л. Сандлер һәм М. П. Калугина комсомол-яшьләргә үзләре үткән хәрби юл турында сөйләделәр.

Ветераннар хөрмәтенә район культура йорты каршындагы үзешчән сәнгатьтә катнашучылар рус, татар һәм чуваш халык көйләрен һәм композиторлар әсәрләрен башкардылар.

Ахырдан ветераннарга истәлек бүләкләре тапшырылды.

## Кыскача хәбәрләр

«Фән һәм глобаль куркынычсызлык»—СССР һәм АКШ фәнни оешмалары катнашында чыгарыла торган яңа журнал шулай дип атала. Ул рус һәм инглиз телләрендә Советлар Союзында һәм Америка Кушма Штатларында чыгарыла.

Аның редакциясе энергетика һәм әйләнә-тирә мохит проблемаларын өйрәнү үзәгендә, Принстан университеты каршында урнашкан.

х х х

Халыкара хокук өлкәсендә ирешкән зур уңышлары өчен юристлар Ассоциациясенең (Нью-Йорк штаты) традицион еллык премиясе М. С. Горбачевка тапшырылды. Бүләкне тапшыруның официаль тантанасында ассоциация җитәкчеләренең берсе Майкл Мэний шуны әйтеп үтте: алдагы еллардан аермалы буларак, премия лауреатын билгеләүне тавышка куеп торуның кирәге булмаган, М. С. Горбачев кандидатурасы тулы берсүзсез хуплау тапты.

**(ТАСС).**

## Ветераннар советында

18 январьда сугыш һәм хезмәт ветераннарының район советы президиумының чираттагы утырышы булды. Анда «Кайгырту» программасын практик тормышка ашыруга бәйле ветераннардан кергән хатлар һәм аларның гаризалары, телдән әйтелгән тәкъдимнәре белән эшләүне яхшырту мәсьәләләре каралды. Президиум 1990 елга сугыш һәм хезмәт ветераннары советының сметасын һәм чаралар планын раслады.

Утырышта каралган мәсьәләләрне тикшерү вакытында президиум членнары һәм совет активистлары И. Л. Сандлер, С. С. Идиятуллин, Н. И. Маслаков, Н. А. Калипаров, К. В. Изотова һәм башкалар тәкъдим һәм тәнкыйть замечаниеләре әйттеләр.

Президиум утырышында КПСС райкомы инструкторы Г. В. Маликова катнашты.

Президиум үзенең алдагы утырышында Г. А. Давыдованың сәламәтлеге какшау сәбәпле сугыш һәм хезмәт ветераннары район советы секретаре вазифаларыннан азат итүне сорап язган гаризасын караган һәм аның үтенечен канәгатьләндергән иде.

Сугыш һәм хезмәт ветераннары район советы секретаре итеп президиум члены Н. С. Суслов расланды.

**Бүгенге санда**

1. САЙЛАУ АЛДЫ МӘШӘКАТЬЛӘРЕ
2. СӨТЕҢ СЫЙФАТЛЫМЫ?
3. «ГАИЛӘ ҺӘМ МӘКТӘП» ПОЧТАСЫ

# Зур һәм тату гаиләдә

Гаилә—безнең җәмгыятебезнең нигезе, аның киләчәге. Балаларны физик яктан чыныккан итеп үстерү, дөрес тәрбия бирү—һәр ата-ананың бурычы. Әгәр гаилә ышанычлы һәм нык икән, димәк, безнең Ватаныбыз да куәтле.

Моңа бәйләп мин Норлат шәһәрендә яшәүче күп балалы һәм тату Фоминнар гаиләсе турында сөйләргә телим. Гаилә башлыгы Исай Петрович —Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны. Ул фронтка 1943 елда китә. Иң элек Көнбатыш Украинада көрәшкән, ә аннан соң Польшаны немец басып алучыларыннан азат иткән. Шулай итеп, Исай Петрович ил сагында сигез ел хезмәт куйган. Аның сугышчан батырлыгы Ватан сугышы ордены һәм Германияне җиңгән өчен медале белән билгеләп үтелгән. Армия сафларыннан өенә 1950 елда гына әйләнеп кайткан һәм шунда ук Норлат тимер юл станциясенең ягулык складына грейдерчы булып эшкә кергән. Аннан соң ул Норлат разведка бораулавы идарәсенә эшкә күчә. Ул биредә 17 ел эшли һәм үзен тырыш, хезмәт сөючән итеп күрсәтә. Идарә җитәкчеләре аның эшенә югары бәя бирәләр—Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр белән бүләклиләр. Күп еллар эшләгәннән соң, ул 53 нче СМУга төзүче-монтажчы булып эшкә күчә. Бер урында озак эшләү солдатның үз профессиясенә тугърылыклылыгы, ныклыгы турыда сөйли. Ул биредән лаеклы ялга китә. Ләкин Исай Петрович кул кушырып утыра алмый, үзенең туган йортына әверелгән эшеннән, коллективыннан аерылмый. Ә бит ул биредә үзенә дуслар тапты, шуңа да бүген дә хезмәт куя.

Исай Петровичның хатыны Надежда Ивановна да иренә тиң энергияле һәм җитез хатын. Балалары нәни вакытта ул эшләмәде. Шуны да әйтергә кирәк: ул заманнарда балалар ясле-ләре һәм бакчалары аз иде, шул сәбәпле күп кенә аналар эшли алмады. Балалары бераз үскәч, Надежда Ивановна Норлат разведка бораулавы идарәсе балалар ясле-бакчасына эшкә керде. Аннан соң ире хезмәт итә торган 53 нче СМУ га күчте. Ул пенсиягә дә әлеге оешмадан китте.

Вакыт сиздерми дә үтә икән. Фоминнарның балалары да үсеп җитте. Ә бит алар сигезәү— 6 малай һәм ике кыз үстеләр. Мәктәптә яхшы укыдылар, өйдә әтиәниләренә булыштылар. Фоминнарның балалары турында тик мактау сүзләре генә әйтәсе килә. Аларның барысы да хезмәт сөючән һәм тыйнаклар. Гади эшче гаиләсендә туып үскән балалар югары һәм махсус урта белемгә ия булдылар. Ә бит аларга вуз һәм техникумнарга укырга кергәндә читтән булышучы булмады, алар профессия һәм киләчәккә юлны үзләре сайлый белделәр. Моның сере нәрсәдә соң? Минемчә, монда бернинди дә сер юк. Фоминнар гаиләсендә кешелеклелек, шәфкатьлелек, тыйнаклык һәм намус җиңә. Ата белән ана үз балаларында хезмәткә мәхәббәтне кече яшьтән үк тәрбияли алдылар, кешеләрне сөяргә, һәрвакыт дөреслектән барырга, намуслы булырга өйрәттеләр. Ә бит халыкта: алма агачыннан ерак тәгәрәми, дигән әйтем йөри. Бу нәкъ Фоминнар гаиләсенә тәңгәл килә. Аларның олы уллары Володя Мәскәү финанс-экономия институтының Белгород филиалын тәмамлады һәм хәзер шушы шәһәрдә үк тәэминат буенча инженер булып эшли. Рус кызына өйләнде. Икенче уллары Николай АПО ның җаваплы работнигы. Ул авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча баш инспектор вазифаларын үти. Читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Евгений Казан финанс-экономия институтын тәмамлады, Башкортстанның Туймазы шәһәрендә эчке эшләр бүлегенең БХСС бүлегендә эшли, милициянең өлкән лейтенанты, өйләнгән. Аның хатыны—татар кызы. Алеша Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлады һәм районның ремтехпредприятиесендә шофер булып эшли. Сергей белән Оля Димитровград шәһәрендә укыдылар. Аларның икесе дә сөт промышленносте техникумын тәмамлады. Иң кечкенәләре Валерий Совет Армиясе офицеры — Горький югары хәрби училищесын тәмамлады һәм Чита шәһәрендә хезмәт итә.

Күргәнебезчә, Фоминнарның балалары үзләренә тормышта юл тапканнар. Аларның һәркайсының үз гаиләләре, үз тормышлары. Хәзер Исай Петрович һәм Надежда Ивановна икәү генә калдылар. Ләкин аларга күңелсезләнергә вакыт юк. Балалары һәм оныклары көн саен килеп торалар. Фоминнарның зур һәм тату гаиләсендә унике онык үсә.

Фоминнар гаиләсен чын мәгънәсендә интернациональ гаилә дип атарга була. Бу гаиләдә татарлар, руслар һәм чувашлар бергә бәйләнеп, тату яши. Алар берберсен яхшы аңлыйлар, хөрмәт итәләр. Зур гаиләнең гомуми теле—рус теле. Ата белән ана чувашлар. Ләкин балалары үз телләрендә сөйләшә белсәләр дә, укый-яза белмиләр. Чөнки алар рус мәктәбен тәмамладылар.

—Без балаларыбыздан канәгать һәм үзебезне бәхетле саныйбыз, — диләр Фоминнар.—Алар безгә мораль һәм материаль яктан булышалар. Бәйрәмнәрдә котлау открыткалары белән бергә бүләкләр дә алабыз.

Әнә шулай яши Фоминнарның тату һәм зур гаиләсе.

**З. ИМУКОВА.**

## Шат булыр идек

Иске Чаллы авылы кешеләре Норлат—Иске Чаллы маршруты буйлап автобус йөри башлагач, чиксез сөенгәннәр иде. Дөрес, автобус авылга ике километр килеп җитмичә туктый иде. Ул күпер иске, техника һәм кешеләрне һәлак итү куркынычы булганлыктан шулай иде. Хәзер яңа тимер-бетон күпер төзелде, әмма шоферлар иске тукталышка «гашыйклар», күрәмсең, гел шундагы тукталалар. Халыкка авылга җәяү китәргә туры килә. Элек Норлаттан Иске Чаллыга билет бәясе 30 тиен иде, хәзер 45 тиен. Әмма без 60 тиен дә түләргә риза, тик автобус авылга кадәр барсын иде. Ә бит көзгеязгы пычракларда, кышкы салкыннарда ике километр араны җәяүләп үтүе җиңел түгел.

Беркөнне яшь балалы ана шофердан авыл үзәгенә кадәр илтүне сорады. Ләкин аңардан: «Әгәр миңа рөхсәт итсәләр, өйләрегезгә кадәр илтеп куяр идем», дигән җавап ишеттек.

Авылда яшәүче бар халык —карты-яше—рейс автобусын авыл үзәгенә кадәр йөртергә рөхсәт сорый. Әгәр шулай булса, без бик шат булыр идек.

**Н. ШУВАЛОВ,**
**В. БОРИСОВ**



**Җәмилә Закирҗановна Гобәйдуллинаның мөстәкыйль рәвештә эшли башлавына 20 ел вакыт узып та киткән. Җәмилә бу вакытның 13 елын районара сәүдә базасында склад мөдире ярдәмчесе булып эшләп узды-ра. Тыйнак, намуслы, гадел эшчене биредә хөрмәт итәләр. Склад мөдире Әлфия Насыйбулловна Хөснетдинова да аның турында яхшы фикердә. Бишәү эшлиләр алар биредә. Зур материаль кыйммәтләр булган складта күмәк эшләү, билгеле, аеруча җаваплылык, гаделлек сорый. Җәмилә боларны бик яхшы аңлый.**

**Аяк киемнәре, тукымалар складында эшләүчеләрнең көннәре мәшәкатьле уза: товар кабул итәргә, сәүдә нокталарына җибәрергә кирәк һәм бу эшләрнең барысы да төгәллек, пөхтәлек таләп итә. Җәмилә Закирҗановна һәм аның иптәшләре һәрчак дустанә, бер гаиләдәй эшлиләр һәм менә шушы дуслык уңышлар китерә дә. Склад коллективы 1989 елны планнарын арттырып үтәп каршылады һәм яңа елга яхшы старт алды.**

**Рәсемдә: сәүдә базасы кладовщигы Җ. Гобәйдуллина.**

## Бүләкләр һәм янгын

Яңа елда күбебез бүләкләр ала. Ул шулай гадәтләнелгән инде. Әмма Яңа ел бүләкләре белән бәла-каза да килгәли.

Янгын сакчылыгы хезмәткәрләренә Яңа ел «бүләкләре» булып янгын чыгу хәбәрләре килде. 3 январьда ит комбинатында кер юуу урыны янды. 9 январьда Ломоносов урамында торак йортта янгын чыкты. Балаларның ут белән уйнавы нәтиҗәсендә, хуҗалык 500 сум зыян күрде. Болары әле берни түгел. Шул ук көнне Мир урамының 35 йорты беренче фатирында электр гирляндаларында кыска ялганыштан чыршыга ут каба. Янгын хуҗалыкка зур зыян алып килде.

Янгыннарның күбесенчә балаларның ут белән шаяруыннан килеп тууы турында күп сөйлибез. Әмма саклык, аларны кисәтү турында аз уйлыйбыз. Бер кыз баладан янгынның нидән килеп чыгуын һәм аның нинди куркыныч тудыруын сорагач, ул җавап бирә алмады. Димәк, балалар бакчасында да, мәктәптә һәм гаиләдә дә бу темага сүз алып баручы булмаган.

Әйе, безнең балаларыбызда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча элементар белем дә юк. Биредә ата-аналар, тәрбиячеләр һәм укытучыларның гаебе зур.

Шулай булгач, янгын чыгу очрагы булганда, кемгәдер үпкәләргә урын юк. Биредә без олылар гаепле.

**Р. ТАТЬЯНКИНА,**
ППЧ-48 инструкторы.

## ХАЛЫК ИГЪТИБАРЫНА!

Сез газдан файдаланасыз. Аның белән сак булыгыз! Кухня бүлмәсен җилләтергә онытмагыз! Чөнки чыккан газ һава белән кушылып шартлау хасил итәргә мөмкин. Әгәр бүлмәгездә газ исе сизсәгез шырпы сызмагыз, электр приборларын кабызмагыз, тәмәке тартмагыз. Бу очракта барлык газ краннарын яки баллон винтелен ябарга, ишек-тәрәзәләрне ачарга һәм бинаны җилләтергә, 2—28—58 телефоны буенча авария бригадасы чакыртырга кирәк.

Газ приборлары белән әгәр алар колонкага, мичкә, су җылыту бакларына тоташтырылган булса, аеруча сак булырга кирәк. Бу очракта газдан файдалану чараларын нык сакларга.

Юллыкларның төзек булмавы агулануны, янгын яки шартлау хасил итүне тудыручы берүдән-бер сәбәп түгел. Газ приборларыннан саксыз файдалану да бәхетсезлеккә китерергә мөмкин.

Газ приборларын чиста тотыгыз, алар белән эш итүгә балаларны, исерек хәлдәге кешеләрне, аның белән эш итә белмәүчеләрне җибәрмәгез. Газ-үткәргечләргә бау тартмагыз, плитә өстенә киптерергә әйберләр элмәгез!

Фатирыгыздан киткәндә барлык краннар да ябылганмы икәнлеген тикшерегез. Газ белән эш итү мәсьәләсенә кагылышлы сорауларыгыз булса, 2—28—58 телефоны буенча газ службасына мөрәҗәгать итегез.

**НОРЛАТ ГАЗ СЛУЖБАСЫ.**

## БЕЛДЕРҮ

**«Норлатнефть» НГДУсының технологик идарәсенә бульдозер машинистлары, К-700, К-701 тракторчылары, токарьлар кирәк. Түләү—вакытлы-премиаль. Уртача айлык хезмәт хакы 200 дән алып 250 сумга кадәр.**

**Редактор урынбасары**
**Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: редактор—2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь—2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—15—63, агропромышленность бүлеге—2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды. Асия Моратханова верстка ясады. Клара Бобкова басты. Корректор—Зөлфия Вәлиева.**

**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 9. Тираж 3.851.**